**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 28 сентябрь № 712

г. Казань

Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләренә мөнәсәбәттә сервитут урнаштыру турында килешү буенча түләү күләмен билгеләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{25}$ статьясындагы 2 пунктның 2 пунктчасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләренә мөнәсәбәттә сервитут урнаштыру турында килешү буенча түләү күләмен билгеләү тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\712.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 28 сентябрь, 712 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләренә мөнәсәбәттә сервитут урнаштыру турында килешү буенча түләү күләмен билгеләү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләренә мөнәсәбәттә сервитут урнаштыру турында килешү буенча түләү күләмен исәпләү кагыйдәләрен билгели.

2. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары территориясендә урнашкан Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләренә мөнәсәбәттә сервитут урнаштыру турында килешү буенча түләү зурлыгы, әлеге Тәртип белән башкасы билгеләнмәгән булса, түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$СП = \frac{Р_{ап} \cdot П_{зу}}{12} \cdot N,$$

монда:

СП – сервитут өчен түләү зурлыгы, сум;

$Р_{ап}$ – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җир өчен аренда түләве турында» 1995 ел, 9 февраль, 74 нче карары нигезендә исәпләнгән еллык аренда түләве зурлыгы, кв.метр өчен сум;

$П_{зу}$ – сервитут таралган җир кишәрлеге мәйданы, кв.метр;

N – сервитут билгеләнгән айлар саны.

Бу чакта аренда түләвен исәпләгәндә җир кишәрлегеннән файдалануның рөхсәт ителгән төреннән чыгып, җир салымы нормасына карата төзәтү коэффициентлары кулланыла.

3. Татарстан Республикасы шәһәр округлары территориясендә урнашкан һәм даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, яисә гомерлек мирас итеп калдырыла торган хуҗа булуга, яисә арендага бирелгән Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләренә мөнәсәбәттә сервитут урнаштыру турында килешү буенча түләү зурлыгы җир кишәрлегенә әлеге хокукларның сервитут урнаштырганчы һәм урнаштырганнан соң булган базар бәясе аермасы буларак билгеләнә, аны бәяләү эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнары нигезендә бәйсез бәяләүче билгели.

_______________________